ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
КАРАР

31 октябрь, 2023 ел. № 5

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Суровка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставы,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 14 ноябрь көнне 2023 елның сәгать 18.00 Суровка авылында Новая, Мира, Дружбы 1-37 һәм 49-62, Юности, Строительная, Индустриальная, 1 нче Строительный тыкрыгы, 2 нче Строительный тыкрыгы, 3 нче Строительный тыкрыгы , 4 нче Строительный тыкрыгы, Строительный юлы, Вишневая, Кленовая, Северная, Столбовая, Заречная 26-27 санлы урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 14 ноябрь көнне 2023 елның сәгать 19.00 Суровка авылында Молодежная, Сиреневая, Раздольная, Посадская, Васильковая, Земляничная, Камская, Бирюсинка, Дружбы 38-48 һәм 63-74, Светлая, Отрадная, Южная, 70 лет Победы, Интернациональная, Лазурная, Спортивная, Тукая, Пушкина, Гагарина, Парковая, Подрядная, Крайняя, Ясная, Ключевая, Хорошая урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 15 ноябрь көнне 2023 елның сәгать 18.00 Суровка авылында Чехова урамында, Заречная, Октябрьская, Авангард комплексы, 1 Мая урамынарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Халык җыенын уздыру өчен Суровка авылы яшәүчеләренең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру;
2) Юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу);
3) Электроматериаллар сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

4) Купфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү (койма сатып алу һәм урнаштыру)

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Суровка авылы, Поперечная урамы, балалар мәйданчыгы янында.
7. Халык җыенын икенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Суровка авылы, Молодежная урамы, балалар мәйданчыгы янында.
8. Халык җыенын өченче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Суровка авылы, Чехов урамы, 1а йорт янында үткәрергә («СУНАМИ» кибете янында).
9. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.
10. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
11. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева